ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ
ОЖЕМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

СОВЕТ УЗЮМСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Таш-Чишма. Тел. 3-50-10

"21" гыйнварь 2019 ел №2

# КАРАР

## Өҗем авыл җирлегенең 2019 елга наркотикларга каршы чаралар планын раслау турында

2010 елның 9 июнендәге 690 номерлы Россия Федерациясе Президентының «2020 елга кадәр Россия Федерациясенең Дәүләт наркотикларга каршы сәясәте стратегиясен раслау турында" Указы нигезендә, авыл җирлегендәсәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга һәм наркотик чаралар куллануны кисәтүгә юнәлдерелгән 2019 елга чаралар планы һәм авыл җирлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Өҗем авыл җирлегенең 2019 елга наркотикларга каршы чаралар планын расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән көннән соң үз көченә керә.

Өҗем авыл җирлеге башлыгы: Вәлиев А.Т.

Әтнә муниципаль районы Өҗем
авыл җирлеге башлыгының
2019 елның 21 гыйнварындагы
2 номерлы карары белән расланды

Өҗем авыл җирлегенең 2019 елга наркотикларга каршы чаралар планы

| № п/п | Башкарылучы чаралар | Башкару срогы | Үтәүчеләр |
|---|---|---|---|
| 1. Наркотикларнызаконсызкуллануһәм наркомания таралуныкисәтү | | | |
| 1.1 | Хокук саклау һәм сәламәтлек саклау органнарыхезмәткәрләренең наркотикларны законсыз куллануның хокукый һәм медицина аспектларын яктырту максатында мәктәп укучылары, авыл яшьләре белән очрашуларны системалы рәвештә уздыру. | Ел дәвамында | Авыл җирлеге администрациясе,<br><br>Өҗем гомуми белем бирү мәктәбе<br><br>Өҗем авылы РФ Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге (килешүбуенча) |
| 1.2 | Яшьләр акцияләре үткәрү:<br><br>«Наркотикларсыз дөнья» акциясе<br><br>Бөтен дөнья сәламәтлек көненә багышланган Акция<br><br>«Без СПИДка каршы»протест акциясе | <br><br>май<br><br>июнь<br><br>декабрь | Өҗем гомуми белем бирү мәктәбе<br><br>Иске Өҗем, Ташчишмә авыл клублары<br><br>Иске Өҗем, Ташчишмә авыл клублары<br><br>Иске Өҗем, Ташчишмә авыл клублары (килешү буенча) |
| 1.3 | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән спорт ярышлары, турнирлар үткәрү | Ел дәвамында | Авыл җирлеге администрациясе,Таш-Чишмәбалалар бакчасы (килешүбуенча) |
| 2. Наркотикларның законсыз әйләнешен кисәтү буенча чаралар | | | |
| 2.1 | Наркотиклы үсемлекләрнең законсыз чәчүлекләрен ачыклау буенча оператив-тикшерү чараларын уздыру, наркотик әзерләүчеләрне, аны йөртүчеләрне тоткарлау. | май-октябрь | РФ Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге(килешү буенча) |
| 2.2 | Авыл җирлеге территориясендә кыргый киндерне һәм законсыз чәчүлекләрне ачыклау һәм юк итү буенча чараларны тормышка ашыру | Июнь октябрь | Авыл җирлеге администрациясе,<br><br>РФ Эчке эшләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | министрлыгының Әтнә районы буенчабүлеге (килешүбуенча) |
| 2.3 | Наркотик чаралар кулланучы затлар турында исәп-хисап мәгълүматларын тикшерүне системалы рәвештә гамәлгә ашыру | Ел дәвамында | РФ Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге Таш-Чишмә ФАПы, Кызыл-Утар ФАПы (килешү буенча) |
| 2.4 | Наркотик матдәләр булган үсемлекләрне законсыз рәвештә үстерүгә,шулай УК җәмәгатьчелек арасында наркотиклар куллануга карата тискәре мөнәсәбәт булдыруга,административ һәм җинаять җаваплылыгын аңлату максатыннан Авыл җирлеге торак пунктларында яшәүчеләр белән аңлату эшләре, җыелышлар үткәрү. | апрель - май | Авыл җирлеге администрациясе, РФ Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге (килешү буенча) |
| 2.5 | Авыл җирлеге территориясендә чит ил гражданнарының килүен исәпкә алу һәм контрольдә тоту. | ай саен | Авыл җирлеге администрациясе,<br>Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча миграция пункты (килешү буенча) |
| 3.Наркотикларны медицинаныкы булмаган куллануга юл куйган затларны дәвалау, эшкә яраклылыгын торгызу һәм реабилитацияләү | | | |
| 3.1 | Наркотиклар, психотроп матдәләр кулланучы гражданнарны ачыклау | Ел дәвамында | РФ Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге,Таш-Чишмә ФАПы,Кызыл-Утар ФАПы (килешү буенча) |
| 3.2 | Сәламәтлек саклау учреждениеләрендә наркотик һәм башка психотроп матдәләргә ирекле үтепкерүне булдырмау. | Ел дәвамында | Таш-Чишмә ФАПы<br>Кызыл-Утар ФАПы |

Өҗем авыл җирлеге башлыгы: Вәлиев А.Т.